Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение
«Центр развития ребенка» - детский сад № 46 «Золушка»
г. Альметьевска Республики Татарстан

# "Балалар бакчасында адаптация чоры"

## әти-әниләр өчен консультация

Әзерләде: музыка җитәкчесе Галиева Н.Р.

**2019 г.**

# "Балалар бакчасында адаптация чоры"

## әти-әниләр өчен консультация

Балалар бакчасы проблемасы - яхшымы ул, начармы, бирергәме анда баланы, юкмы , иртәме, соңмы -  һәр гаиләдә туа торган проблемаларның берсе.

***Балалар бакчасында адаптация чоры***



*Балалар бакчасы проблемасы - яхшымы ул, начармы, бирергәме анда баланы, юкмы – иртәме, соңмы һәр гаиләдә туа торган проблемаларның берсе.*

*Бу проблеманың актуаль булуы гаиләнең матди хәленнән дә , ата- аналарның шөгель төренә дә бәйле түгел, һәр гаиләнең үз тәҗрибәсе, балалар бакчасына карата уңай һәм тискәре фикерләре бар.*

*Бала,балалар бакчасына тиз һәм кыенлыклар кичермичәм генә иялэшсен өчен аны алдан ук әзерли башларга кирәк.*

*Яңа килгән балаланың балалар бакчасына килгәч тә, өйдәгедән бөтенләй аерылып торган яңа шартлар, яңа мохиткә килеп эләгүен күп кенә ата-аналар аңлап та җиткерми.*

*Сабыйга яңа учреждение, яңа кешеләр, таныш түгел иптәшләр, өлкәннәр, режим моментларына иялэшеп китүе бик тә авыр.*

*Ата- аналар да бала өчен борчылалар, балалар бакчасы таләпләренә иялэшәләр.Шул ук вакытта тәрбиячегә дә бала һәм ата-аналары белән якын мөнәсәбәтләр урнаштыруы җиңел түгел.*

*Бала, балалар бакчасына карата уңышлы адаптаөия чоры үтсен өчен, ата-аналарның бакчага карата уңай мөнәсәбәттә булулары, балада да шундый фикер тәрбияләүләре шарт.*

*Баланың адаптация процессына аның психик һәм физик үсеше, сәламәтлеге, чыныгуы, үз-үзенә хезмәт күрсәтә белүе, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән коммуникатив аралашуы, сабыйның шәхси үзенчәлекләре, ата-аналарның борчылу дәрәҗәләре дә тәэсир итә. Әгәр алда әйтеп үткәннәр балада булмаса яки түбән дәрәҗәдә булса микросоцияль шартларда адаптация чоры авыррак үтә. Баланың сәламәтлегенә зыян килә, чөнки эмоциональ стресс реакциясе үсеш ала.*

*Фәнни тикшеренүләрдән чыгып адаптацион процессның өч фазасын билгеләп үтәләр:*

1. *(подострая фаза) Авырлык килү, сөйләшү, аралашу кимү (дәвалыгы 1 ай).*
2. *(подострая фаза)Баланын үз-үзен тотышы адекват, бары тик аерым параметрлар буенча үсеш темпында тоткарлыклар күзәтелә (дәвамлыгы 3-5 ай).*
3. *Компенсация фазасы, үсеш темпларынын тизләшүе, нәтиҗәдә балалар уку елы азагына алда әйтелгән тоткарлыкларны җиңеп чыгалар, үтәләр.*

***Балалар бакчасында адаптация чорын үтү берничә дәрәҗәгә бүленә:***

1. *Җиңел адаптация.*

- *Вакытлыча йокы бозылу (7-10 көндә тәртипкә салына).*
- *Аппетит (10 көндә)*

- *Адекват булмаган эмоциональ реакция (тискәреләнү, йомылып калу, агрессив булу h.б.) уенда, сөйләшүдә, ориентлашуда активлашу (20-30 көндә).*

1. *Уртача адаптация (барлык әйтелгән кимчелекләр тагын да кискенрәк формада һәм озаграк бара: йокы, аппетит 20-40 көндә, ориентлашу эшчәнлеге (20 көн), сөйләм активлашу (30-40 көн), эмоциональ халәт (30 көн), хәрәкәтләнүе активлашуы 30-35 көндә. Бала авырый (мәсәлән ОРВИ, ОРЗ).*

2. *Авыр адаптация (2 айдан 6 айга кадәр)*

*Алда әйтеп үтелгән барлык билгеләр дә авыр формада үтә. Аппетит кимү (ашаганын косып чыгару очраклары), кискен йокы бозылу, иптәшләре, өлкәннәр белән контактка бармау, агрессив булу, берүзе калырга тырышу. Авыр адаптация чоры үткән балалар беренче 10 көндә һәм иләшеп киткәнче кабат-кабат авырыйлар.*

1. *Бик тә авыр адаптация.( Ярты ел һәм аннан да күбрәк дәвам итә). Сорау туа: бу баланы бакчага йөртергә кирәк микән?*

*Ничек кенә булмасын, ничек кенә баланы бакчага әзерләмәсеннәр, бала, бигрәк тә беренче көннәрне зур стресс кичерә.*

*Адаптациягә, баланың темпераменты да йогынты ясый. Сангвиниклар һәм халериклар тиз ияләшә. Ә флегматик һәм меланхоликлар авыррак. Алар әкренрәк, балалар бакчасы темпына җитешә алмыйлар: ашау, биремнәрне үтәү, киенү, урамга җыену алар тарафыннан әкрен башкарыла.*

***Практикада күренгәнчә авыр адаптациянең сәбәпләре:***

- *Гаиләдә режим сакламау һәм аның мәктәпкәчә учреждение режимы белән тәңгәл килмәүе*
- *Балада билгеле бер үзенә генә хас гадәтләр булуы (бигрәк тә тискәре),*
- *Уенчыклар белән уйный белмәү;*
- *Гади культура- гигиеник күнекмәләр формалашмавы;*
- *Ят кешеләр белән үз-үзен тота һәм аралаша белмәве.*

*Балалар бакчасына әзерләнүнең 1 этабы (әзерлек этабы) ата- аналар өстендә. Бала мөстәкыйль рәвештә ашый, киенә һәм чишенә белергә тиеш.*

*2 этаб ( төп этаб) ата- аналар һәм тәрбиячеләргә йөкләнелә. Бу очракта ата-аналар тәрбияче белән тыгыз элемтәдә булу зарур. Алар баланың һәр гадәтен, психик, физик үсешен нинди дәрәҗәдә булуын тәрбиячегә җиткерергә тиешләр. Шул вакытта гына бала тәрбиячегә ышана, аның тарафыннан яклау таба башлый.*

*3 этаб (йомгаклау). Бала балалар бакчасына 2-3 сәгатькә килә башлый. Исегездә тотыгыз! Беренче чиратта кәеф, аппетит, соңыннан гына йокы тәртипкә салына.*



***Балалар бакчасына адаптация җиңел үтсен өчен түбәндәгеләрне үтәү зарур:***

1. *Балалар бакчасы белән танышу. (бәйрәмнәргә, уен мәйданчыгына килү )*
2. *Баланың гадәтләрен тәрбиячегә җиткерү (имезлек, бармак суыру)*
3. *Режим саклау.*
4. *Бакчага бергәләп әзерләнү. (киемнәр сатып алу, сорауларга җавп бирү.)*
5. *Бала барында балалар бакчасы проблемалары турында сөйләшмәскә, бакча хезмәткәрләренә карата тискәре фикер белдермәскә.*

*Адаптация чоры тәмам дип исәпләнә, әгәр:*

- *Бала аппетит белән ашаса;*
- *Вакытында тыныч йоклап китеп, көйсезләнмичә вакытында уянса;*
- *Кызыксынып уйный башласа;*
- *Теләп аралаша башласа.*

